ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 17 декабре**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 3624**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 35 нче йортның техник торышын кабат тикшерү нәтиҗәләре турында.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 декабрендәге ведомствоара комиссиясе актын һәм бәяләмәсен карап, адресы: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 35 й. адресы буенча урнашкан йортның тузу һәм яшәү өчен яраклы булу дәрәҗәсен кабат тикшерү турында «Стройэкспертиза» СЭЦ» 2016 елның 24.11. 13-16 номерлы эксперт бәяләмәсен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамы, 35 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортның яшәү өчен яраксызлыгын авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип танылган акт һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 06 октябрендәге 213 номерлы ведомствоара комиссиясе бәяләмәсе нигезендә кабат расларга.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин